«Килешенгән»
Чаллы шәһәре Башкарма
комитеты җитәкчесенең урынбасары
Халимов Р.М.

«Раслыйм»
ТР МДН мөфтие
Камил хәзрәт Сәмигуллин

# НИГЕЗЛӘМӘ

**ТАССР төзелүгә 100 ел тулу уңаеннан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына мөселманнарның татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча берләштерелгән XII Рәсәйкүләм турниры**

## 1. Максат һәм бурычлар:

- татар халкының милли спорт төрләрен һәм традицияләрен актив тормыш рәвешенә кертү;
- мөселманнар арасында татар милли көрәшен һәм кул көрәшен киң җәелдерү һәм үзара дуслык җепләрен тагын да ныгыту;
- мөселманнарда сәламәт яшәү, чыдамлык, түземлек сыйфатларын тәрбияләү өчен шартлар тудыру.

## 2. Бәйгене үткәрү вакыты һәм урыны:

- бәйге Чаллы шәһәренең «Витязь» спорткомплексында 2020 елның 11 апрелендә уздырыла (адресы: Яр Чаллы проспекты, 23 йорт, «Челныгорстрой» тукталышы. Телефоны: 8(8552) 56-65-99).

Шәхси-команда ярышлары олимпия системасы буенча үткәрелә:

- иртәнге сәгать 8 дән 9 га кадәр – катнашучыларны үлчәү;
- сәгать 9 дан 9.30 га кадәр – вәкилләр һәм хөкемдарлар җыелышы;
- сәгать 10.00 да – бәйгене ачу.

## 3. Бәйгенең җитәкчелеге:

- бәйгеләрне әзерләүче һәм уздыручы гомумҗитәкчелек – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Чаллы шәһәре башкарма комитеты һәм Чаллы шәһәре мөхтәсибәте.
- төп хөкемдар – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев.
- турыдан-туры җитәкчелек вазыйфасы Чаллы мөхтәсибәте һәм хөкемдарлар коллегиясенә йөкләнелә.

## 4. Бәйгедә катнашучылар һәм бәйгеләрне уздыру шартлары:

- бәйгеләрдә 18 яшьтән кече булмаган, ***намаз укучы***, тиешле физик әзерлеккә һәм медицина рөхсәтенә ия мөселманнар гына катнаша ала;
- көрәш буенча авырлык категорияләре: 65; 75;. 85; 95; 105 һәм 105 килограммнан артык;
- 50 яшьтән узган көрәшче-ветераннар татар милли көрәшендә абсолют категориядә бил алыша. Аларга, бәйгедә катнашу өчен, йөрәк электрокардиограммасы булу мәҗбүри;
- кул көрәше буенча авырлык категорияләре: 70 килограммга кадәр, 85; 85 килограммнан артык;

- үлчәнгәнгә кадәр, ***катнашучылар намаз уку кагыйдәләрен белү буенча тест үтәргә тиеш;***

- бәйгедә катнашучыларның үзләре белән паспорт, ИНН, СНИЛС булырга тиеш;

***- бәйгеләр җирәбә тәртибе буенча уздырыла;***

- бәйгедә катнашучылар барысы да спорт киеменнән һәм түбәтәйдән булырга тиеш.

**5. Бүләкләү:**

- һәр авырлык катеґориясе җиңүчеләренә диплом һәм кыйммәтле бүләк тапшырыла;

- җиңүче командага Кубок бирелә;

***- үз авырлык категориясендә беренче урын яулаганнар арасында җирәбә салына, отучыга турнирның төп бүләге – Хаҗга юллама тапшырыла.***

**6. Финанс чыгымнары:**

- турнирны әзерләү һәм уздыру, җиңүчеләрне бүләкләү өчен тотылган бар чыгымнарны бәйгене оештыручылар хәл итә;

- бәйгедә катнашучы спортчыларның, хөкемдарларның, тренерларның чыгымнарын (юл хакы, туклану, яшәү урыны) аларны командировкага юллаучы оешмалар түли.

**7. Гаризалар:**

- командировкага җибәрүче оешма һәм табиб тарафыннан расланган гаризалар 2020 елның 11 апреленә кадәр хөкемдарлар коллегиясенә тапшырыла;

- бәйгедә катнашучы һәркемнең бәхетсезлек очракларыннан страховка кәгазе булырга тиеш;

- үлчәнер алдыннан һәр катнашучы үзенең паспортын күрсәтергә тиеш.